


Я75 НО/2

*Нәгыйм Ярмөхәммәтов*

# *Аулак өйле яшьлегемне сагынам*




*Тәтер-Арслан - 2006*

Я 75

Яшьлек...



***Минем 1951 елда 16 яшемдә төшкән фотосурәтем***

Хыялларга чумып, киләчәкне күз алдына да китерә алмыйча яшисең, яшисең дә, һаман алга карап, кояшка омтылган чәчкә кебек үсәсең. Уйланасың. Төрле уйлар сине алга алып бара. Укыйсың, китаплар, фильмнар аша җир шары буенча сәяхәт кыласың. 14-15 яшьләрдә ниндидер хисләр уянып, егетләр кызларга, кызлар егетләргә тартыла башлый. Ташкан хисләреңне белгертә алмыйча хафаланасың, йокы кача.

Без үскән үткән гасырларда кыз белән егет очрашса да, кеше күрмәсен дип кача-поса башкарыла иде. Яшьләр хәзер ничек яши, ничек очраша? — дигән сорау һәрвакыт мине борчып килде. "Кичләрен ничек үткәрәләр, үзләрен ничек тоталар?" — дигән сорау сыйныф җитәкчесе буларак мине борчый торган иде. Шушы сорауларга җавап табу исәбе белән олы кеше булсам да, дискотекалар карарга барам. Клуб тирәләрендә, урамда булам. Яшьләр соңгы 10-15 елда бик нык үзгәрде. Дискотекаларда аңлаешсыз музыка астында нәрсә генә кыйланып сикермиләр, боргаланмыйлар. Кызларның өстендә кыска итәк, күкрәген генә каплаган җиңсез кием, бил ачык, кендекләрендә алка, беләкләрендә егетләрдә дә, кызларда да татуировка (аны вакытлыча дип әйтәләр). Егетләр кызмача, клуб тирәсендә, артында пиво, аракы чөмерәләр. Кызып алгач, билгә кадәр чишенеп, күлмәкләрен салып, утларны сүндереп, сикерәләр.

Менә замана! Ә без үскәндә кызмача егет очраса аның белән кызы-егете аралашмады, аңа нәфрәт белән карыйлар иде. Клублар суык булганга, безнең күңел ачу, очрашу урыны булып аулак өйләр торды. Анда да кызлар кертмәсә, барып керә

40/2
ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ БИБЛИОТЕЧНАЯ СИСТЕМА
Б/Н-2

алмыйсың, туң тәрәзәне өреп, эретеп кызыңны күзлисең. Яшьләр әйтергә мөмкин: "Яшәгәнсез инде," — дип. Юк! Бер дә алай түгел, аулак өйләрдә җырлап-биеп үзеңнең хисеңне егет кызга, кыз егеткә җиткерә иде. Бу онытылган очрашуны, тәртипне безнең яшьлек хәтирәсе итеп сезгә язып калдырам.

Шулай, аулак өйнең бүген кемнәрдә булуын ишеткәч, кичне түземсезлек белән көтеп аласың. Егетләр белән җыйналышып авылның аулак өенә гармун уйнатып Әче урамына ( Чәчкә урамы) җырлашып юнәләбез. Яшьләр, буыннар катарга да өлгермәгән үсмер малайлар бит инде без. Менә таныш капкага килеп җиткәч, тынып калдык. Янәсе, читләр ишетеп-белеп калмасыннар, укытучы Дәүләтшина Зәйнәп, Әсфәндиярова Зәйтүнә апалар белмәсеннәр, комачаулап йөрмәсеннәр. Аннары зуррак малайлар килсә, безгә сан булмый, шунысы да бар.

Ишек эчтән бикле. Тәрәзәдә ут юк, эчтән бик нык каплап куелган. Тыңлыйбыз, тавыш та юк. Була бит арада бер җор малай, тәрәзәгә чиртеп, сигнал бирә. Эчтә кинәт бер нәрсә челтерәп куя, һәм кызлар түзә алмый, дәррәү көлеп җибәрәләр. Безнең түбәләр күккә тия. Ә йөрәкләр үзебезгә ишетелерлек итеп, бер кат күлмәк астында тыпырчына.

"Бисмиллагызны укый-укый керегез, егетләр!" — дигән булды гармунын култык астыннан алып Мансур һәм үзе алдан атлады. Килеп кергәч, бер-бер артлы кул бирешеп тезелешеп утырган кызлар белән күрештек.

— Урын тапсагыз, утырыгыз, егетләр! — дигән булдылар кызлар. Матур итеп көлеп алдылар.

— Урын да булмагач, ник чакырдыгыз?

— Абау, мәхәббәтсез...

— Мәхәббәтем булмаса, килеп тә йөрмәс идем.

— Мәхәббәт капчыгы...

Кызлар бердәм көлеп җибәрделәр. Мин иптәшемнең кабыргасына сиздерми генә төртеп алдым. Ә ул аңлады һәм: "Миңа штраф, җәзалагыз! — диде.

— Биесен! Җырласын! Кәҗә булып кычкырсын!

Мансур гармун тартты, теге иптәш бер аягын алга сузып, усал сарык аягын тыпырдаткандай, биергә чыгу хәрәкәте ясады. Китте бөтерелеп, тыпырдап әйләнә-әйләнә бер кызга килеп басты. Икәүләп әйләнделәр. Шуннан китте парлашып биюләр. Барысы да бер кат биеделәр.

Тәмам, — диде Минрахман биюне туктатырга теләп.

— Арырлык булгач, килмәс идең.

— Ә, алаймы? Торыгыз, әйдә, барыбыз да биибез!

Бар да бии, җилкенә, мич ыспутындагы куыклы лампа җемҗем итә, биючеләргә күз кыса. Ара-тирә такмаклар да ишетелеп куя: "Бие-бие Гайфулла, биегән кеше бай була". Өзгәләнә гармун, ярсый яшь йөрәк, һәр буын хәрәкәттә, әгәр урамда берәр үтүче булса, бу өйнең бүрәнәләре дә ни өчен селкенеп-селкенеп тора, дияр иде. Шәйбәк тиз генә чыгып тирә-якны карап керде, ул-бу юкмы, укытучылар килмәгәнме?

Ниһаять, күңелләр хушланды, буыннар бушады. Мансур да ишарәләп, бармакларын берничә мәртәбә җиз итеп төймәләр өстеннән йөгертеп алды. Чыркылдашып утырыштык.

— Әйдәгез, йөзек салабыз!

Без амин тотарга әзерләнгән кебек, куш учларыбызны алга суздык. Рима йомшак кына бәләкәй бармагы белән безнең учларыбызга тиеп китте. Юк, йөрәк кылларыбызга чиртеп китте ул. Әгәр өнебездә түгел, төшебездә килеп учыбызга "йөзек салса" да, теләсә нинди озын көйләргә дә тыпырдатып биеп алырга риза булыр идек. Йөзек кемдә, шул бии, җырлый, бии, я шигырь сөйли иде.

— "Кем сукты?" — уенына кем баса?

Йөгереп килеп, Шәйбәк уртага баса. Уң кулы белән уң күзен тота, сул кулының уч төбен читкә каратып уң як култык астына куя. Калганнары аның артында барысы да уң кулының баш бармагын өскә күтәреп торалар. Берсе килеп кенә уртадагы кешенең кулына тиз генә суга һәм баштагы торышына кире кайта, ә уртадагысы әйләнеп карап, кем сукканын белергә тиеш. Белмәсә — урынында кала, белсә, табылган кеше аның

урынына баса. Уен шулай дәвам итә. Малайлар кулының суканын һәм кызлар кулының кагылуын шәйләп аласың инде, югыйсә.

— Йолдыз саныйбыз, йолдыз!

Бер малай, бер кыз уртага чыгып, аркалары белән терәлеп, туп-туры итеп басалар. Барысы бергә: "Бер, ике, өч!" - дип санагач та, башларын борып кына бер-берсенә карыйлар. Әгәр икесе бер якка карап, битләре биткә тисә, өй алдына караңгыга "йолдыз санарга" чыгарып җибәрәләр. Өйалдындагыларга өйдән һәркем үз теләгән әйтә:

— Мәхәббәтегез көчле икән, магнитыгыз дөрес күрсәтәме?

— Ничә йолдыз күренә?

Шулай итеп, йолдызлар да санап алдык.

— Яңа уен — "Каеш ашатабыз." Кемдә солдат каешы бар?

Малайлар һәм кызлар парлашып утыралар. Берсе уртада каешны урталай бөкләп тоткан. Беребезгә пар юк. Менә шул әйтә: "Ал кирәк тә гөл кирәк, миңа гармунчы Мансур кирәк!" Ә ул икенче бер кыз белән утыра. Каешлы Муллаәхмәт сорый бу кыздан: "Безгә Мансур кирәк, биреп җибәрегез!"

Кызның да Мансурны тиз генә биреп җибәрәсе килми: "Үземә дә бик кадерле, кешеләргә тәтеми!" Теге парсызы ачуланып: "Ә алайса, каеш белән суктырып алып бир! Каеш ашасын! Сук бишне, уч төпләре янганчы!" (Бердән алып унгача сугарга мөмкин). Әгәр кыз аны бирәсе килмәсә, ничә тапкыр суксалар да, риза була, ләкин бирми. Егетләргә кыз эзләгәндә дә шулай ук эшләнә. Кем дә кем нык яратуын белдерәсе килсә, ул каеш белән уч төбенә никадәр суксалар да, түзеп тора. Монда инде Мансурның да китәсе килми.

— Аңа сукма! Үзем алам җәзасын, мә кулымны, мин түзәрмен, җанашым!

Бу уенда бер парны да аера алмадылар. Шулай булмый ни, безнең бер-беребезгә күз атып йөргән чаклар бит. Монда инде татарның "Ир бирмәк — җан бирмәк" дигән борынгыдан килгән әйтеменең дөреслеге чагыладыр. Уены-чыны бергә.

"Кызлар, мин тын белергә барам!" — диде яулыгын бөркәнгән



бер кызыбыз.

Агач кашыкны суга манып алырга кирәк. Кеше күрмәсен. "Агач кашык алдыңмы?" - дип сорыйлар аңардан. Ул ым белән генә аңлатты да, чыгып та йөгерде.

— Галия апа әлүмин кашык алып барган икән "тын белергә", күпме генә тәрәзә төбендә торса да, бернәрсә ишетмәгән, — диде, яктыга талпынучан күбәләк кебек талпынып, мине "Нәгыйм" дип йөргән кыз.

— Әлүмин кашык ярамый шул. Суга да манчылмагандыр әле, — дигән булдым мин дә, белдекле кеше сыман.

Ул арада күз бәйләп иптәшеңне тоту һәм исемен әйтү уены башланып китте. Уртада күзе бәйләнгән Минрахман кулларын алга сузып, әкрен генә бара һәм кинәт борылып берәрсен тотарга омтыла. Тирә-якта кычкырып-кычкырып алалар, кисәү агачы тоттыралар, мендәр кочаклаталар. Берәрсенең киемен биреп, ул кием кемнеке икәнен белсә, ул кешене күзен бәйләп уртага бастыралар.

"Тын белергә" киткән кыз кайтып керде. Аны әйләндереп алдылар. "Миниса апа өендә берүзе генә, җырлый-җырлый чынаякларын сөртә. "Көтегез, кайтырбыз дидек, өйләрдә калганнарга", — ди. Сөенечемнән башкасын тыңлап та тормадым. Абыем хезмәттән исән-сау кайта икән, Алла боерса, кызлар, — дип сикергәләде ул һәм күзләреннән яшьләре дә чыкты шикелле. Кызлар "и" дә "и" килеп, аны кочаклап алдылар, ә без, малайлар, сөенешеп бер-беребезгә карап алдык.

— Минем абыйның хаты озак кына килми торгач, безнең әни дә "тын белергә" барган иде. Зәйнәп абыстай әйткән: яңага чаклы бик озак бит әле, ачыгырбыз инде, балакайларым, дигән.

— Моны ничек аңларга?

— Бәй, балтырганга кадәр вакыт бар бит әле, бик кыен булыр инде, үлмәсәк ярар иде, — дигәнне аңлата бит.

— Шулай шул, — дип ризалашалар аулак өйдәгеләр.

Шәйбәкнең күзен бәйләп, уртага бастырганнар иде, кызларның уйныйсы килмәде. Уеннар сүрелде. Шәйбәк — җор

малай, кызлар янына барып, "чыш-пышлап" алды да, без тезелешеп утырдык. Мансур саратскиен тартып җибәрде. Көмеш кыңгыраулар ми сызыклары өстеннән йөгереп үткәндәй булды. Әллә нинди, без белмәгән көйләрне дә белә икән бу Мансур! И, булгач та була адәм баласында моң! Аның һәр буыны хәрәкәттә. Миңа аның дүртпочмакланып торган борын очыннан да көй чыгып торган кебек тоела. Ирексездән, үзем дә сизмәстән, үземнең борын очымны тотып карадым. Әллә ничек булды инде, аңламадым. Ә ул җиңелчә генә такмакларны да уйнап сыздыра. Үзебез яраткан "Наза", "Комсомолка Гөлсара" көйләрен дә дәртләнеп-дәртләнеп уйный, күңелдәге моңсу дулкыннарны тарата. Өй тирәсен карарга Ягъфәрне чыгарып җибәрәбез. Янәсе, теге Зәйнәпләр, Зәйтүнәләр, я булмаса, башка укытучылар безне тыңлап йөрмиләрме, — дип. Юк икән.

Җырлашып утырганда, мин күз уңымда гына тоткан сөйкемле кыз үзенең кульяулыгын идәнгә ташлады.

— "Кульяулык ташлау" уенын башлыйбыз! — дип кычкыра ул. Кызлардан берәрсе нинди уен башласа, без инде каршы килмибез, шуны гына көтеп торабыз.

"Кульяулык ташлау" — сизмәстән генә бер кызның яки малайның кульяулыгын алып идәнгә ташлыйлар (үзе ташласа да ярый). Тезелешеп утырган кызлар көлә-көлә малайларның исемнәрен бер-бер артлы атыйлар. Кульяулык иясе кыз, үзенә ошаган малайның исемен ишеткәч, кульяулыгын идәннән ала. Шуннан соң малай белән кызны караңгы өйалдына чыгарып җибәрәләр. Алар анда серләрен уртаклашалар.

Өйалдында бернәрсә күренми. Мине сайлаган кыз капшалап мине килеп тотты. Шунда минем бөтен тәнем йомшарды, тез буыннарыма әллә ни булды — гәүдәмне күтәрә алмагандай тоелды, маңгаема тир бәреп чыкты, кымшанырга да куркып торам. Минем кызым үзен иркенрәк хис итә кебек, колагыма якын гына аның тавышы ишетелде.

— Нә-гыйм, иртәгә мәктәпкә соңга калмабыз микән? Әллә нигә...



Мин шушы килеш ни әйтергә дә белми, озак тордым шикелле. Ни дип җавап бирергә дә, тагын ни эшлиләр икән, дип торганда ишекне эчке яктан шакыдылар һәм шаян сүзләр белән:

— Җитәр, үбешеп иреннәрегезне юкартып бетермәгез!

— Бәрәңге ашарлык калдырыгыз.

— Кочаклаша беләсезме?

— Кайсыгыз яравайлаша?

Бу сүзләрне ишеткәч, мин бөтенләй коелып төшеп, суга батырган тавык кебек бөрешеп, тирләп киттем. Кая инде ул вакытта үбешү дигәннәре.

Кемгә ни дип җавап бирә алмый торганда, минем янымдагы кыз тагын дилбегәне үз кулына алды: "Тыңлама син аларны. Без дә үзләрен шулай ирештерербез әле. Ярыймы, Нәгыйм?"

Мин тагын ни дияргә белмәдем, баш кагып куйдым. Караңгыда синең баш какканыңны ул күрәме соң инде?

— Оҗмахта озак торырга ярамый... Керегез!

— Әйдә, керик булмаса, — дидем мин һушыма килеп.

Кирәк бит, шул вакыт кылт итеп исемә килеп төште. Һәрвакыт ишектән кергәндә, хатын-кызларга алдан юл биреп керергә дигәнне. Караңгыда, ул алдан керсен дип юл биргәндә, күкрәге...күкрәге сыдырылып үтте. Мин артыннан бусаганы ничек атлаганымны да тоймадым. Өйдә кызлар көлештеләр, ә малайлар мине нәрсәләр диптер канатландыралар. Мин...-мин аларны аңларлык түгел идем. Тиеп кенә киткән кечкенә, йомры гына, каты гына бу күкрәкне гомер буе тоеп яшәдем ахры.

Уен дәвам итте, тагын Минрахман белән бер кызны өйалдына чыгарып җибәрделәр.

— Кысып-кысып кочакла, кызлар кочаклаган саен үсә ул, — дип көлеп калдылар. Боларга да һәркем үз теләген әйтеп калырга тырышты. Минрахман кызларга чаярак иде, үпте, кочакладымы икән?

Кайбер парлар икешәр мәртәбә чыгып керделәр, күрәсең,

сәбәпләре булгандыр.

Нинди генә уен уйнасак та, бер-беребезгә ияләшү, сынау, үзебез белгәнне иптәшебезгә өйрәтү, тагын әллә нинди ачышларның ләззәтен тою иде. Кеше җылыныр өчен кулларын учакка суза, ә кызлар һәм егетләр бер-берсенә булган назга тартыла.

— Җыр очлау осталары, әзер булыгыз!

Кызлар теләсә нинди җырның яртысын әйтәләр: "Биек тауның башларында...", "Кулымдагы йөзегемнең исемнәре..." (нинди генә исемнәр әйтмиләр, көләләр) һәм әкрен генә унга кадәр саныйлар, аннары бер малайдан икенче өлеше ничек икәнен сорыйлар. Әгәр белми калсаң яки үзең уйлап чыгармасаң — штраф: бию, җырлау, әтәч, кәҗә, сарык булып кычкыру, эт булып өрү, сыер булып мөгерәү, сәке астына кереп үрмәләп чыгу.

"Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Әптерәй..."— диделәр дә шып тuктадылар кызлар. Берсе унга кадәр саный, калганнарга күзләрен елтыратып малайларның уйлау сәләтен тикшерә. Без тынып калдык. Юк бит, җыр сүзләрне рифмалаштырып кына булмый. Уф, ярый әле миңа эләкмәде. Шәйбәк җырны очлап чыгарды:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әптерәй,
Минем сөйгән ярым
Үбә белми аптырый.

Әй көлештек инде, кул аркалары белән күзләрне сөртергә туры килде.

Менә тагын "Биек тауның башларында, утыра катык тәпәне, — дигән җырны очларга әмер булды. Уйлап тордык та, малайлар көлеп җибәрдек.

Шунда кызлардан икенче әмер булды; начар сүзле җыр очы булса, аулак өйдән чыгарып җибәрәбез. Кемнең генә начарлыкка барып, аулак өйдән колак кагасы килсен инде. Санау унга якынлаша, малайлар җитдиләнә.

— Нәгыйм очласын, Нәгыйм!



Мин бу җырны очлый алмадым, штрафка икенчесен җырлап күрсәттем. Шунда иптәшем Мансур гармунын "Җомга" көенә өздереп уйнап җибәрде. Кыңгыраулары, һай, үзәккә тия. Үзем бик оста җырлый белмәсәм дә, башлап кына җибәрәм.

Иркәм мине үпкән иде,
Миләш күләгәсендә.
Иркәм миңа сәлам язган,
Торган вәгъдәсендә.

Суга барсам тукталамын
Шул миләш төпләрендә,
Утырып хатлар язамын
Сиңа — сөйгәнемә.

Борыламын да карыймын
Су юлы миләшенә.
Күтәрмен, бәгърем карамый
Ятларның киңәшенә.

Коела миләш чәчәге
Чиләккә суларына;
Күзләрем алмый карыймын
Кайтасы юлларыңа.

Малайлар һәм кызлар дәррәү күтәреп алалар. "Нәгыйм" дип озын итеп өзелеп эндәшкән кызым да әллә нинди хисләргә бирелеп җырлый, яшь күңеле өзгәләнә, талпына, җырлап үзенең хисен, тойгысын аңлатырга тырыша. Җыр артыннан җыр, көй артыннан көй уйнала. Менә күңелле! Җырлар безнең яшьлектә ниндидер халыкчан, моңлы, үзенә тартып тора иде. Хәзерге яшьләрнең әллә нинди аңлашылмаган калын тавыш белән җырлаган чит ил җырларына кушылып бию, ләззәтләнүе мине аптырата.

Ул вакытларда безнең күңелләрне талпындырып "энәдән-

җептән чыккан" "Яшь имәннәр шаулый", "Алсу чәчкә тотып син чыгарсың минем каршыма", "Комсомолка Гөлсара" дигән җырлар, авыздан-авызга күчеп җырланып безгә, яшьләргә килеп җитә торган иде. Ул вакытларда радио юк. Халык моңы җил кебек авылдан-авылга тарала, җырлана иде. Бу җырларның исемен дә, авторын да кем икәнен кем белгән инде. Без инде кызлар җырлаганда кушылабыз. Мансур өздерепме өздерә гармунда. Кайчан өйрәнеп беткән ул аларны? Безнең йөрәкләребез күкрәк читлегендә терпелдәп тора, күңел канатланган, оча гына әллә кайларга. Юк, әллә кайларга түгел, теге минем белән өйалдына чыккан кызга. Ул бик мөлаем булып күренә миңа, зур түгәрәк күзләренең төбәп каравы, матур иреннәренең сизелер-сизелмәс кенә елмаю белән миңа сөенечле хәбәр әйтергә теләгән кебек. Ә тавышы гел минем күңел кылларын гына чиртә, башка бер кеше ишетми кебек аны. Мин исердем, хозурланып исердем. Бәлки аруым да җиткәндер. Бала-чага булсак та, өй эшендә дә катнашабыз, утын кисәбез, мал асларын тазартабыз, мәктәптә укыйбыз. Анда да эш күп, тик теге кыз гел истә. Башка кызлар-егетләр дә таштан яралмаган, күзләребез көлеп торсалар да күңелләребез сыкрап, елап тора.

Малайлар уенны икенчегә бордылар. Ым кагып кына кызлар белән сөйләштеләр дә... без тышка чыгып киттек.

Күктә биниһая йолдызлар җемелдәшә, кояш чыгышы ягыннан, күк йөзенә нииндидер яктылык сибелгәндәй, чүмечкә охшап тезелешкән йолдызлар, "егетләр, кадер-хөрмәт күрдегез, акылыгызга утырып әллә яраткан кызларыгызны калдырып өйләрегезгә кайтасызмы?" — дигән төсле тоела.

Иртәгәсен дәрескә баруны да исәпкә алып, кызлар белән хушлашырга өйгә керәбез. Өйдә тәрәзә япмалары алынган, җиделе лампа уты басылган, кызлар да йокларга әзерләнгән. Алар белән хушлашып, тагын җыйналырбыз әле, дип сөйләшеп, өйләргә таралышабыз.

Менә бу вакыйгалар, аулак өйләр безнең буын яшьләренә бик яхшы таныш һәм күңелләребезнең хәтерендә онытылырлык түгел. Кайчан һәм кайда гына "...аулак өйле һәм гармунлы яшьлегемне сагынам", — дип җырлый башласалар, олыгайган булсак та, күңелләр сулкылдап куя, күзләргә мөлдерәп яшь килә. Ләкин үзебез һаман горур калабыз, сер бирмибез. Ә шулай да, ничек кенә булмасын, сагындыра, сагындыра аулак өйле һәм гармунлы яшьлек еллары.

Без дусларыбыз, иптәшләребез, яшьтәшләребезнең һәм сөйгәннәребезнең күңел җылысын тоеп яшәдек. Бер урамда үскән биш егеттән бер үзем генә калып, узганнәрне искә алып моңланам. Сез — Минрахман, Шәйбәк, Ягъфәр, Муллахмәт бу дөньяны ташласагыз да, минем күңелдә, истә. Без бердәм хезмәт җимеше белән тукландык, киендек, түземлелеккә өйрәндек. Шушы түземлелек безне көчле итте, акыл бирде. Татар канлы, татар телле татар итте.





НО/2
СТЕРЛИБАШЕВСКАЯ ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ БИБЛИОТЕЧНАЯ СИСТЕМА
Б/Н-2

**Литературно-художественное издание**

**Нагим Арсланович Ярмухаметов**

**«Вспоминая задорную молодость»**
(текст на татарском языке)

Редактор Абдуллин И.Г.
Художник Акчулпанов Н.А.
Технический редактор Акчулпанов Н.А.
Корректоры Галимова Г.Н.
Ибатуллина Ф.З.

---

Сдано в набор 25.01.06 г. Подписано в печать 29.03.06.
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная. Гарнитура «Pragmatica».
Печать офсетная. Тираж 100 экз. Заказ N70.
ГУП РБ РИК «Стерлибашевские родники»
РБ. с Стерлибашево, ул К.Маркса, 102.